# Бакчабызда “Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы “н ачу тантанасы – “Туган телем – иркә гөлем”

Бакчабызда «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» ачу тантанасын «Туган телем – иркә гөлем» исеме астында ачып җибәрдек. Татар балалар бакчасы булганлыктан, халкыбызның көнкүрешенә, бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә, йолаларына, җыр-биюләренә, милли уеннарына һәрдаим басым ясалып килә.

Быел инде балаларга үз милләтебезне, Идел буе халыкларын тагын да кинрәк, баерак итеп өйрәтүне максат итеп куйдык.









